УДК 821.512.145

*Д.Ф. Заһидуллина*

# ФАТИХ ӘМИРХАН ШӘХЕСЕНӘ ЯҢА КАРАШ

В статье анализируется 6-й том 6-томного академического издания «Әсәрләр» Фатиха Амирхана, посвященный материалам и документам личного характера известного писателя и общественного деятеля, журналиста и публициста. В нем представлены дневники, не опубликованные статьи-приложения к дневниковым записям, многочисленные (158) письма (от него и ему), документы, которые раскрывают малоизвестные страницы жизни и творчества Амирхана. Эти материалы формируют новый взгляд к личной истории писателя.

**Ключевые слова:** татарская литература, Фатих Амирхан, послереволюционная ситуация, письма, дневниковые записи

The article analyzes the 6th volume of the 6-volume academic edition “Əsərlər” by Fatikh Amirkhan, which is dedicated to the materials and documents of the famous writer and public figure, journalist, and essayist. It includes diaries, unpublished articles that serve as appendices to the diary entries, numerous (158) letters (from and to him), and documents that reveal little-known aspects of Amirkhan’s life and work. These materials provide a fresh perspective on the writer’s personal history.

**Keywords:** Tatar literature, Fatikh Amirkhan, post-revolutionary situation, letters, diary entries

Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнгән 6 томлы Фатих Әмирхан «Әсәрләр»енең беренче томнары 2024 елда нәшер ителә башлады [1]. Чагыштырмача зур булмаган вакыт аралыгында аның соңгы, 6 нчы томы да дөнья күрде [3]. Ф. Әмирханның көндәлек язмалары, хатлар, аңа бәйле документлар тупланган бу томны әдипнең шәхси тормышына, фикер-карашларына, рухи дөньясына тәрәзә дип булыр иде. Чөнки биредә ул, әдәби-публицистик әсәрләрендәге кебек, киң укучылар аудиториясе, татар халкы белән түгел, тар даирә белән сөйләшә, серләшә, кайгы-борчулары, шатлык-өметләре белән уртаклаша. Шуңа да аның затлы шәхесе, сурәте-образы яңа яклары белән ачылып китә.

Фатих Әмирхан дүрттомлыгының 4 нче томына «Көндәлек язмалар» өлешчә кертелгән булса да [10: 184–220], бу басмада беренче тапкыр тулысынча биреләләр. Язмалар 1921 елның 7 октябрендә башланып, өч ай дәвамында алып барылган. Шулай булса да, аларда шәхси кичерешләр илдә барган үзгәрешләр контекстында калкулана, инкыйлабтан соңгы хәл-күренешләр 1917 елга кадәрге вазгыять белән чагыштырып бәяләп барыла. Боларны совет хакимияте көчәйгән, тормышның барлык өлкәләрен биләп алган бер дәвернең тарихи-документаль тасвиры дип карап булыр иде.

Бер үк вакытта сәяси шартлар үзгәрүнең кешеләр психологиясенә тәэсире, тормыштагы хаосның иҗтимагый аңны һәм кыйммәтләрне җимерүе дә аермачык күренеп, укучыны уйлануларга этәрә. Беренче язмада ук әдип үз тормышын өметсез бер халәттә дип таба: «Хәзер минем шәхси тормышымда шул язасы килүдән башка юанычым да юк». Каләм яңа юллар сызган саен, мондый кәефнең бик күпләр өчен уртак булуы ачыклана бара.

Һәрчак тормышка өмет белән караган, оптимизмны җуймаган әдипне күп нәрсәләр гаҗәпләндерә һәм кайгыга сала: сүз белән эш аерылу («Кәгазь өстендә РСФСРда авыруларга дәвалар буш бирелә, ә вакыйгада хәзер үзеңә кирәкле бер дәваны табар өчен, күп акчаң өстенә, аптека тирәсендәге спекулянтлар арасыннан белеш-танышларга да малик булырга кирәк»), яшәүнең кыйммәтләнүе, совет цензурасы («Галимҗан Ибраһимов мәҗмугасында мин ачлык турысында ул теләгән рәвештә язылган мәкалә бирә алмыйм»), советча «уплотнение», кеше кадере калмау (Талип Гайнуллинга хат язу), күз буяу (спекуляция һәм караклык белән көрәшү мәсьәләсе), караклык («Капитализм эше булган караклыкның коммунизм строенда көннән-көн тәрәккый итә, чәчәк ата баруы чын-чынлап искиткеч») һ. б. бик күп күренешләр әдипнең каләм очына эләгә. Бигрәк тә халыкның донос белән мавыгуы, советларның илне күрә торып җимерүе, ачлык, хөкүмәтнең эчкечелекне алга сөрүе чарасызлык чигендә бәян ителә. Бу урында Ф. Әмирханның – инкыйлабка, аның татар халкына ирек алып киләсенә чын күңелдән ышанган кеше булуын да күздән җуймаска кирәк. Шуңа да аның тәнкыйте инкыйлабның ялгыш асылына түгел, бәлки аны ялгыш юлдан алып киткән советларга юнәлтелгән. 11 октябрьда язып куйган: «Менә шунда да хикмәт: коммунистлар партиясе үзенең гакылсыз хәрәкәте, яхшы максат юлында иң начар чаралар да истигъмаль ителергә ярый дигән, дөньяда инде күп мәртәбәләр тәрбия ителеп тә һаман бәни адәмгә зарар итә килгән былчырак бер кагыйдәгә ябышуы, властьне кирәгеннән артык сөюе, гаммәгә бер уенчык итеп карап, аның психологиясен вә шул психологиядән чыккан заруриятне хисапка алырга теләмәве, биргән вәгъдәләрендә гаммәне алдаудан чирканмавы, үзен тәнкыйть иттермәү өчен һәртөрле хөрриятләрне бууы белән социальный революцияне, шул гомум төрек-татар милләтенә файдадан башка нәрсә китермәячәк социальный революцияне провалить иттерде: вакытсыз башлады, ахмак рәвешчә алып барды, мәгънәсез сурәттә пыш иттереп сүндерде», – дигән сүзләре тагын бер кат шул карашын ассызыклый.

Язмаларда Ф. Әмирханның үз иҗатына ачыклык кертә торган мәгълүматлар да шактый. Әйтик, «Ачлар мәҗмугасы»на материал сайлауга бәйле, «Беренче ашкыну» [2: 271–280] буларак йөргән өзекнең шактый күләмле итеп планлаштырылган (повесть?) «Ситдыйк мәхдүм» әсәреннән алынганлыгы әйтелә. «Карт кыз» исеме белән телгә алынган текст бүгенге көнгә кадәр табылмаган, ул әдипнең билгесезлектә калган әсәрләре булу мөмкинлеген искәртә. Гомумән,

биредә Ф. Әмирханның әлеге авыр елларда да актив рәвештә иҗат белән шөгыльләнергә теләгәнлеге, каләме ярдәмендә халкына хезмәт итү омтылышының саклануы аермачык.

Әлбәттә, көндәлекне бик кыска вакытта алып баруы, шуннан соң язмаларның өзелүе әдипнең 1920 елларда дөньяга карашын эзлекле күзалларга мөмкинлек бирми. Көндәлек ахырына теркәлгән берничә материал аның үз күргән-кичергәннәрен мәкалә итеп язып баруына да ишарә ясый кебек. Әмма бу вакытта (эчтәлегенә караганда, алар 1925 елда язылган булырга ошый) мондый материалларны бастырырлык матбугат органы калмау да мәгълүм.

Язмаларда Әмирханның Г. Ибраһимов белән мөнәсәбәтләренә шактый зур урын бирелгән. Шуңа күрә аларга бераз ачыклык кертеп узу мәгъкуль булыр.

1907–1909 елларда Уфа шәкерте Г. Ибраһимов Казанда Г. Тукай һәм Ф. Әмирхан чыгарып барган «Әлислах» газетасы белән хезмәттәшлек итә, үзенең язганнарын шунда бастыра. Бу хезмәттәшлек яшь егетне татар мәдәни дөньясына таныта, 1909 елда Казанга күчеп килергә рухландыра. Бу вакытта Ф. Әмирхан – журналист, язучы булып танылган, каләм тибрәтә торган яшьләрнең әйдәманнарыннан берсе. Тик 1909 елның июлендә «Әлислах» ябыла, нәтиҗәдә Г. Ибраһимов «Йолдыз»га эшкә күчә, үзенә химаячелек күрсәткән шәхесләр белән арасы суынуга китергән берничә вакыйга була.

1910 елда Г. Тукай авторлары мәгълүм әдәби әсәрләрдән төзелгән беренче (күптән көтелгән!) хрестоматия – «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре»н нәшер итә. Г. Ибраһимовның аңа рецензиясе китапның исеме белән «Йолдыз»ның 1911 елгы 4 гыйнвар санында басыла. Сүзне мондый уку китапларының кирәклегеннән башласа да, автор Тукайны текстлар сайлаганда артык вәгазьчелеккә, үгетнәсыйхәтчелеккә бирелеп китүдә гаепли, кайбер әсәрләрнең рухы татарча булмауга игътибар итә [4: 69–72].

Шул ук елда Г. Ибраһимов «Йолдыз»да Г. Тукайның «Күңел җимешләре» җыентыгына (5 апрель) [4: 75–76] һәм «Мияубикә» әсәренә (21 июнь) [4: 77–78] рецензияләр яза. Икенче язмада әсәрнең шигырь булып чыкмавы хакындагы фикер Г. Тукайның күңеленә тия – ул шушы ук газетаның 30 июнь санында «Аз гына төзәтү» исеме белән кискен генә җавап бирә [8: 197].

Г. Ибраһимов тарафыннан «Йолдыз»ның 1911 елгы 15 ноябрь санында бастырылган «Хәят» язмасында Ф. Әмирханның шул исемдәге повесте [4: 79–80], 1912 елгы 13 март санында дөнья күргән «Зур романнар»да «Урталыкта» романы хакында сүз бара [4: 100–101]. Алар авторының гүзәл «Хәят» әсәре турындагы «сай чыккан җирләр дә күп», «яшь күңелләрнең беренче мәхәббәте сыек чыга. Хәят тибының табигый икәнлеге хакында да бик зур шөбһә бар», «Әсәргә “милли хикәя” диелгән. Мин моның яңлышлыгы хакында кул кисеп бәхәсләшә алам...» кебек фикерләре белән килешү авыр.

Моңа Ибраһимовның каширләр белән судлашуы килеп кушыла. Әлеге тартыш 1911 елда, Г. Ибраһимов «Вакыт» газетасының 1911 елгы 1 октябрь санында бастырган «Казан китапчылары» исемле мәкаләдән башлана [5: 98–102]. Аңа җавапны Ш. Әхмәров «Йолдыз»да (1911, 29 ноябрь) бирә, Г. Ибраһимовның дөньяга шәкерт күзе белән каравына ишарәли. Г. Ибраһимов та сүзсез калмый: «Казан китапчыларының рәддиясе хакында» (1911, 4 декабрь) мәкаләсендә наширләрнең үзен плагиатлыкта гаепләүләре турында әйтә [5: 108–111]. 1912 елның 11 февралендә булып узган Третейский суд Ибраһимов раславының дөреслеккә туры килмәвен белдерә. Бәхәскә нокта куела, әмма аның ямьсез тәэсире кала.

Шуның артыннан ук, 1912 елның февраль саннарында «Идел» газетасында Г. Ибраһимов үзенең иң бәхәсле фәнни-тәнкыйди хезмәтен – «Татар шагыйрьләре»н бастыра башлый [4: 112–181]. Тулы килеш хезмәт 1913 елда Оренбургта аерым китап булып дөнья күрә һәм татар мәдәни җәмгыяте тарафыннан гаять тискәре кабул ителә. Хезмәтнең Тукай каты авыру вакытта, үлеменә берничә ай калгач нәшер ителүе зур шау-шуга, мәсьәләнең әхлакый, кешелеклелек ягын үзәккә куюга сәбәп була. Казандагы бер төркем йогынтылы татар зыялылары Ибраһимовка бойкот белдерәләр, үз чиратында, бу Г. Ибраһимовның Казаннан Киевкә китеп бару сәбәпләреннән берсе дип фаразлана.

Әлбәттә, Г. Ибраһимовның карашларына да берьяклы гына бәя бирергә ярамый: әлеге дәвердә тәнкыйть – милли мәдәниятне үстерүнең иң туры юлы исәпләнә. Биредә Ибраһимовның татар әдәбиятыннан көчле бер эстетик күтәрелеш көтүен дә онытмау мөһим. Татар әдәбият белемендә бу мәсьәлә инде шактый өйрәнелгән һәм бәяләнгәннәрдән санала, шуңа күрә моңа озаклап тукталуга ихтыяҗ юк.

Г. Ибраһимов Казанга әйләнеп кайтып, «Аң»да эшли башлагач, якын дусларга әйләнмәсәләр дә, Әмирхан белән аралашулары җайга салына. Әмма 1917 елдан соң аларның юллары кабат аерыла. Исхакыйлар чит илгә киткән, Ф. Әмирханнар авыр хәлдә калган мәлдә Г. Ибраһимов әдәбият-мәдәният мәйданында каләм әһелләрен үз тирәсенә туплый, яңа совет әдәбиятының юлын билгеләүчегә әверелә. Әмирхан белән дә аралашып торалар. Моны Г. Ибраһимовның 1921 елның 21 мартында язылган хаты да раслый. Ул – Ф. Әмирхан хатына җавап, Ибраһимовның үз сәламәтлеге хакында сөйләве ихлас, якын кешесенә эндәшкән шикелле тоела.

Ф. Әмирхан көндәлегенә кушымта итеп теркәлгән язмаларны (алар беренче тапкыр 6 нчы томда китереләләр) менә шушы контекстта карарга кирәк. Беренче язмада әдипнең үзенә каршы оештырылган Хәйретдин Вәли мәкаләсен Г. Ибраһимовның көнчелек нәтиҗәсе дип кабул иткәнлеге күренә.

«16 гыйнвар “Сания” операсы куела» дип исемләнгән язмада да әдипнең килеп туган каршылыкка рәнҗеп яшәве сизелә. Үзе белән танышырга килгән кешеләргә ул болай дип эндәшүен тасвирлый: «“Сез

нишләп җуләрләнеп йөрисез?” – дим. Әллә кайчан инде модадан чыккан, әллә кайчан инде Галимҗан Ибраһимовның ләгънәтен алып бетергән, идеологиясе белән “кяфер” булган бер мөхәррир белән, гассафәтеннән курыкмыйча, танышып ятасыз, башыгызга бәласыз үтмәс”, – дим». Язма, асылда, шушы сызлануны, борчылуны белдерү өчен генә язылган.

«Иҗтимагый оятсызлык» дигән текстта кабат шушы каршылыклы мөнәсәбәт калкып чыга. Татар театрының 20 еллык юбилеена бәйле, «татар театрының һәм матди, һәм мәгънәви атасы булган» Г. Кариевне искә төшермәү, Г. Исхакыйны сүгү, үзенең – «моннан 20 ел әүвәл куелган татарча спектакльнең башлап йөрүчесе һәм баш батыр ролен уйнаучысы, кирәк хикәяләремдә, вә кирәк публицистикамда татар театрының башлануы, бара алуы, мөмкин кадәр мәгънәле баруы, мөмкин кадәр сәнаигы нәфисә булудан чыкмавы өчен 12–15 ел эчендә иң кызу каләм көрәше алып барган мин – начармы, яхшымы, ике пьеса хуҗасы, начармы, яхшымы, 20 еллык журналист – юбилейның мәҗлесенә дә чакырылмадым!» дигән сүзләрдә Ф. Әмирханның бу хәлләргә тирән борчылуы ачыклана.

Соңгы язма беренче карашка бу мөнәсәбәтләрдән читкә киткән кебек тоела: ул Кәрим Әмиринең «Сахра баласы» исемле «шигыренә» үтергеч бәя бирә, яңа революцион сүзләр кулланганнан гына язуның әдәби әсәргә әйләнмәвен сарказм белән аңлата. Әмма бу материал да алдагыларына бәйле: ул Ибраһимовларның совет әдәбияты тудыру омтылышын көлке объекты ясый.

Күрәбез: кушымтадагы язмалар 1921 елда Казанда иҗат кешеләре арасындагы каршылыкларны, Ф. Әмирханны уйландырган хәлләрне ачып сала. Бәлки, алар әдипнең татар тормышындагы тискәре күренешләргә бәя белдергән мәкаләләр туплый башлаганын дәлиллидер (яшь вакытта һәр күренеш-вакыйгага матбугат битендә мөнәсәбәт белдереп барырга күнеккән журналист бит ул!). Күрәсең, яшәү шартлары аңа бу язмаларны дәвам итәргә һәм халыкка чыгарырга мөмкинлек бирмәгән.

* * *

Китапта Ф. Әмирхан хатлары һәм аңа адресланган хатлар махсус бүлеккә туплап бирелгән һәм 1902–1925 елларны үз эченә ала. Моңа кадәр Ф. Әмирханның 4 томлыгында – 60 хат [10: 221–304], «Рухи мирас» [6: 116–184] сериясенең 2 нче китабында – 32 хат тәкъдим ителгән булса, 6 нчы томда аларның саны 158 гә җитә. Аларның күбесе Ризван Алушига язылган. Беренче хатлар фикердәшләрнең үз аралашу даирәсе хакында сөйләшү-хәбәрләшү төсендә: җылы юмор белән сугарылган хатларда дөнья һәм гаилә хәлләре дә, татар тормышындагы вакыйгалар да күренеп китә. Бу хатларда ул заман татар җәмгыятендәге күп кенә хәл-күренешләр ачыклана, төгәлләштерелә. Әйтик, 1904 елның 9 февралендә язган хатында [10: 225] Әмирхан шәкертләрнең, реформалар таләп итеп, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен ташлап чыгуларын, моның нәтиҗәләрен бәяләп уза, 75 шәкерттән

торган җәмгыять төзелүне хәбәр итә. Шул ук хатта татар яшьләренең ике спектакль: «Кызганыч бала» һәм «Гыйшык бәласе»н уйнаулары, үзенең нинди рольләр башкаруы әйтелә.

Хатлар бик самими, дустанә язылганнар. Алар бергә-бер серләшү төсен дә алалар: 1906 елның 6 мартында язган хат, күрәсең, дустының, гаилә кору кебек мөһим адым ясау алдыннан, өйләнү мәсьәләсендә фикер соравына җавап бирә. Әмирхан өйләнүнең – азатлыкка киртә салуын искәртә. (Бу урында шунысын да әйтергә кирәк: Ризван Алушиның хәләл җефете Фәрханә Әмирханның да дустына әйләнә, ул аларның икесенә бергә яки ханымның үзенә дә хатлар яза башлый.)

Хатларда иҗтимагый вазгыять гел күренеп бара. Әйтик, шул ук хаттагы: «Йосыф Акчуринны арестовать иттеләр; хәлфәм Гассарны арестовать иттеләр, бәлки үземне ошбу көннәрдә [арестовать] итәрләр» җөмләсе әдипнең гел киеренкелектә яшәвен күрсәтә [10: 229].

1905 елдан, татар вакытлы матбугаты оешкач, хатларда шушы мәсьәлә алга чыга. Бу яктан, 1908 елның 17 апрелендә Ризван Алушиның журнал чыгару хакында сораган фикеренә җавап кызыклы:

«1) Кирәк газета, кирәк журнал әүвәлге ике елда мотлак зарар күрә – фәкать аннан соң гына үз-үзен илтә алырлык дәрәҗәгә җитсә җитә ала.

2) Әгәр газета вә журнал киләчәктә бер ашатып яткырырлык нәрсә булсын дигәндә, баштан бик аз дигәндә өч-биш мең сум акчаң кулда булырга тиештер.

3) Нәшер итә башлаганда мотлак көздән башларга тиештер, чөнки гыйнвар башыннан гына башланганда халык мәсләген вә ышанычын белмичә иштираэ итми. Шулай итеп, яз җитә, ул вакытта дәхи халыкта газета вә журнал һәвәсе калмый» [10: 249].

Шуннан соң журналларның икътисади хәлен күзәтү Әмирханның бу мәсьәләне тирәннән белеп, аларның менеджеры булганлыгын да күрсәтә.

Кайчак ул вакытлы матбугаттагы үз эшчәнлеген дә тәнкыйтьләп уза. Алушига 1910 елның 11 апрелендә язган хатында мондый юллар бар: «“Ялт-йолт”ның әүвәлге номерлары бик сыек чыктылар. Аның өчен мин бик уңайсызландым. Ләкин чынлап язышырга бер дә вакыт арттыра алмыйм. Җәй көне дә буш вакытлар булыр дип уйлый алмыйм, чөнки укуны дәвам иттерергә уйлыйм» [10: 280]. Күпчелек хатларда шушы: вакыт җитмәү һәм укырга теләве – сызылып бара.

1907 елның 25 ноябрь хаты параличланган Фатихның сырхауханәдә дә «Әлислах» газетасында эшләве: баш мәкаләләр, «Дамелла» имзалы язмалар әзерләве турында. «Әүвәлге номерда Казан шәкертләре имзасы белән язылган “Печән базары татарларына ачык хат” та авыруымның куәтле вә көчкә-көчкә генә утырып тора ала торган вакытымда минем кулым белән тәртип ителмештер» [10: 240], ди ул.

Шуңа бәйле, Алушига язган хатларда бик мөһим моментка игътибар юнәлтәсе килә: Әмирханның вакытлы матбугатта дөнья күргән имзасыз язмаларының үзенеке икәнен күрсәтүенә. Бу аның публи-

цистик мирасын тулыландырып, эш колачын дәлилләп килә. Шушы урында Ф. Әмирхан алтытомлыгының 3–5 томнарындагы шактый мәкаләләрнең хатлар биргән мәгълүматка нисбәтле беренче тапкыр әдипнең академик басмаларына кертелүен искә төшерергә мөмкин.

1908 елның 8, 20 мартында, 17 апрелендә Исмәгыйль Аитовка язылган хатлар аеруча нечкә юморы белән аерылып тора [10: 243–249]. Алушига да, Аитовка да юлланган хатларында татар тормышындагы, дуслары арасындагы вакыйгаларны гел көлке белән тасвирлаган Әмирхан үзеннән үзе көлүне дә читкә куймый. Фәрханә Алушига 1908 елның 15 сентябрендә язган хатында ул үзенең гыйшкыннан да көлке ясый: «Казанда нинди яңа хәбәрләр дисеңме? Менә мин монда теге Ш. туташ Камаловага (Серноводскидагы) гашыйк булдым дип исем чыгардым. Яшьләрнең һәммәсе шуны мөзакәрә мәшгульләр. Ник гаҗәпләнәсең? Гыйшык – Йосыф пәйгамбәрдән калган сөннәт ул» [10: 257].

1909 елның 18 ноябрендә Ризван һәм Фәрханә Алушиларга, алардан озак хат килмәүгә борчылып, ул үзе бер хикәячек булырлык көлке ситуация тудыра: «Бу хатны мин фәкать бер генә касд белән язам. Әгәр моннан соң да җавап булмаса, ул вакытта мөәззингә 20 тиен садака керттереп, җәмәгатьтән – мәсҗед картларыннан рухларыгыз өчен һәвел намазы укыттырачакмын. Табигый, үзем дә һәр намаз артыннан рухларыгыз өчен өч “Әхәд” сүрәсен укуны гадәт итенәчәкмен. Сез бичаралар терек (зи хәят) вакытыңызда яхшы ук кешеләр идеңез, әгәр мәрхүм булган булсаңыз, хакыйкатән дә зур тәәссефләр! Тем более, үзегезгә фатиха итәрлек бер бала да калдыра алмадыгыз. Бу бер ихтималга бинаән. Икенче ихтимал: Чита шәһәрендә кибет ачкач, дустишләр белән хат язышмаска да ярый дип уйлавыгыздыр. Әгәр бу ихтимал була калса, миңа “кибетегезне ут себерсен” дип бәддога әйтеп утырудан башка эш калмый.

Шулай да яңадан бер кат әйтеп карыйм әле: теләсә ничек булсын, кирәк үлек булыгыз, кирәк терек булыгыз, кош теледәй бер намә күндерегез» [10: 274].

Күпчелек хатлар татар җәмгыяте, андагы хәл-әхвәл, иҗтимагый-мәдәни вазгыятькә кагыла. Әмирханны яшьләр арасындагы сүлпәнлек, татарларда эчкечелек, бушка вакыт уздыру, милли-мәдәни үсеш өчен капитал булмау барыннан да бигрәк борчый. Бу мәсьәләләр хакында уйлану хаттан хатка күчә. Әдип, күрәсең, бу хәлләрнең сәбәпләре, тамырлары хакында да уйлана. 1910 елны Лев Толстойга язуында [10: 275] ул татарлар арасында эчкечелек таралуның европалашу белән бәйле булу-булмавына кагыла. Европадан килгән уңай күренешләрнең – бик авырлык белән, тискәреләренең – бик тиз үтеп керүен әйтә. Рус язучысының 7 ноябрьдә вафаты, күрәсең, хатның тәмамланмавына һәм җибәрелмәвенә сәбәп булган.

1910 елдан башлап хатларда татар җәмгыятендәге уңай күренешләр дә шатланып бәян ителә. Ризван һәм Фәрханә Алушиларга 1910 елның 6 февралендә язылган хатта мондый юллар бар:

«3 декабрь тарихлы мәктүбтә, син (Ризван) яшьләрдә хәят беткән дип уйлыйм дип язасың. Фикеремчә: бу фикер бөтенләй тугры түгел. Хәзер Казан яшьләре арасында чынлап уку дәвере башланды. Алар үзләренең шул чыпчык авызындагы су кадәрле мәгълүматлары белән “Татар центры”нда эш ярамый икәнен аңладылар, бу сүз окраинада (әтрафта) хезмәт итүче яшьләргә карап әйтелми, чөнки аларның һәрбер кечкенә адымнары да татар тарихында мөһим. Бу ел язга әллә никадәр егетләр имтиханга керәчәкләр» [10: 276].

Шушы ук фикер Ризван Алушига 1911 елның 2 февралендә язылган хатта кабатлана: «Хәзер уку бик модага кереп тора. Бу ел уннан артык кеше аттестат зрелости имтиханына керәмез. Яшьләр вә билхосус студентларымыз татар әдәбияты белән бик интересоваться итә башладылар. Хосусый кружоклар әдәбият тәнкыйте белән иштигаль итәләр. Татар спектакльләре, музыка кичәләре монда хәзер инде бик горфи, бик еш була торган эшләр булып киттеләр. Син (Ризван) белә торган кешеләрдән: Газиз Гобәйдуллин һәм Нәҗип Хәлфин хәзер инде студент булып киттеләр. Гыйльметдин Шәрәф һәм Вафа Бәхтияров (“Әлислах” мөхәррире) бу көннәрдә өйләнергә йөриләр. Исмәгыйль Аитов та шулай ук» [10: 286].

Дустына 1911 елның 3 октябрендә язылган хатта да ул, үзенең дә аттестат алырга имтихан бирүен әйтеп, болай ди: «1) Әүвәлдә син простой гына хәлдә күрә торган кешеләреңнең берникадәрлесе хәзер студент булып киттеләр: Фоад, Хөсәен Ямашев, Габдерахман, Газиз Гобәйдуллин, Нәҗип Хәлфин – хәзер инде ялтыравыклы төймәләр кадап йөриләр. Гомумән Казан яшьләрендә уку, мәгълүмат арта, “шәкерт фикере” кими башлады. Озакламый менә бер зубной врачымыз да була: Ямашев хатыны Хәдичә. Ахры акрын-акрын чынлап та үсә башладык.

2) Казанда хәзер әллә никадәр син белми торган яңа кешеләр заһир булдылар. Коммерческийда укучы утыздан артык татар малайлары, гимназияләрдә укучы кырыкка якын татар кызлары – һәммәсе акрын-акрын үсәләр. Балалыктан чыгып, “кеше” рәтенә керә башлыйлар» [10: 289].

Зур гына бер төркем хатлар газета-журнал идарәләренә адресланган. 1910 елның 23 мартында Әмирхан «Йолдыз» идарәсенә хат яза. Газетаның бер номерында «Фәтхулла хәзрәт» исемле фельетон басылган була. Әдип: «Фельетон көлкеле һәм матур язылган, шуңар күрә укып бетергәнче бер мәртәбә дә иснәмәдем», дип, газетаның «иснәтә торган» мәкаләләр нәшер итүеннән көлеп уза. Ике мәсьәләгә туктала: авторның псевдонимын ачу ярамаганлык; повестьның әһәмиятсез урыннарын тәнкыйтьләү. Шуннан соң ул әсәрнең асылын аңлата: «“Фәтхулла хәзрәт” рисаләләрендә миңа – язучысына матлуб булган нәрсә фәкать мөбарәк хәзрәтемнең хәзинәи фикрия вә рухияседер. Калганнары фәкать канва эшләүче татар кызына марляның әһәмияте кадәр генә әһәмиятледерләр» [10: 278].

Шушы ук язманың икенче кисәге повестька «Вакыт» газетасының бәяләмәсенә кагыла, анда да «танец... вә туташлар» гына игътибарга алынганлыкка борчыла, әсәрнең төп максаты аларны сурәтләү түгеллек хакында сөйли. Әлбәттә, искелекне, шул искелекнең нигез баганалары булган хәзрәтләрне усал сарказм белән тасвирлаган, иске тормышның киләчәге юклыкны, яңа тормышның фән һәм мәдәният юлы белән барачагын раслаган «Фәтхулла хәзрәт», бәлки үз замандашлары тарафыннан аңланып та бетмәгәндер. Моңа әсәрнең бүленеп, газета форматында нәшер ителүе дә комачаулаган булыр. Әмирхан җавабында бер фикер аермачык күренә: ул заман әдәбиятының – житди әдәбият, халык өчен файдалы мәсьәләләрне күтәргән, милли идеаллар формалаштырган әдәбият булырга тиешлеген белдерә.

1913 елның 17 ноябрендә «Аң» журналы укучыларына яңа ел котлаулары да милли идеалларга кагыла: «Яңа ел мөнәсәбәте белән милли талантларымызга күбрәк илһам килүен, зыялыларымызга милли идеалларының мөгаенлашуын, гомуми халкымызга милли мәктәпләремез мәсьәләсенең истикъбалемез өчен файдалы сурәттә хәл ителүен телим» [10: 292], ди Ф. Әмирхан. Шунда ук үзенең псевдонимы – көләргә, тәнкыйтьләргә ярата торган Ташмөхәммәд исеменнән болай дип өстәп куя: «Хәзергә кадәр мин теләгән нәрсәләрнең һаман киресе генә булмый килә, шуңар күрә мин бу яңа елда инде зыялыларымызга күп сүз вә аз эш, мөхәррирләремезгә ялкаулык, хатын-кызларымызга матур күлмәк белән ямьсез тәрбия, гомуми халкымызга бетмәс-төкәнмәс эшсезлек телим».

«Кояш» идарәсенә 1913 елның 30 апрелендә язылган хат әдип иҗатының йөзек кашы булган «Хәят» повестена кагыла. Бик күп укучыларның үзенә повестьның ахырын сорап мөрәҗәгать итүен телгә алып, әдип дусты Тукайның вафаты, кайгылар үзен эштән аерганлыкны белдерә [10: 292].

Газета-журналларга хатларда яшьләргә тәнкыйть тә бар. Әйтик, «Кояш» идарәсенә 1917 елның 18 апрелендә язылган хатта Ш. Бабичның «Көлке капчыгы»на әдипнең «Танс кичәсе» хикәясен урнаштыруын Әмирхан тиеш булмаган эш дип белдерә, тагын кабатланса, судка бирәчәген искәртә [10: 294].

1917 елдан соңгы хатларның адресатлары да, эчтәлекләре дә үзгәрә. Җылы һәм сагышлы хат – Галимҗан Барудига этисе үлеменә бәйле кайгы уртаклашуы өчен хөрмәт белдереп язылган (1921, 28 июль). Анда остазына да, этисенә дә җылы хисләре саркып тора («Соңгы елларда инде эти миңа бер ата гына түгел, бәлки һәм бер иптәш һәм бер дуст та иде: берничә көннәр өйдә булмый торсам, мин аны сагынып, кечкенә балалар шикелле сагынып кайта идем. Менә шунлыктан этинең вафаты миңа ике катлы бер зыяг, мөрәббәгъ бер хәсрәт булды...» [10: 297]).

Шул ук елның 13 октябрендә Зәйнәп Әмирхановага язган хат әдипнең бу кайгы халәтеннән чыгып җитә алмавын күрсәтә. «Минем

настроения яхшы түгел, гомумән тереклектән туебрак, аны авырсыныбрак яшим, сәламәтлегем да яхшы түгел, минем дә этиләр, Нәҗип абыйлар артыннан баруымның мөддәте озак калмагандыр дип уйлыйм, ләкин хәзер андый настроенияләрне хатка язып торуның вакыты түгел, һәркем юатуга мохтаҗ, караңгы уйлар һәркемнең үз өстендә җитәчәгеннән артык. Шуңар күрә бу турыда сүз озайтмыйм» [10: 298], ди ул.

Каләмдәшләренә язган хатлар, нигездә, әдәби процесс белән бәйле. Алар арасында М. Гафурины – егерме еллык (1923, 6 июнь) [10: 300], М. Корбангалиевне (1925, 6 декабрь) [10: 303] 30 еллык хезмәт бәйрәме белән котлаулар да урын алган.

Хатлар Әмирханның мәдәни тормыштагы хәлләргә битараф кала алмавын сөйлиләр: «Наркомпрос һәм татар театры дирекциясенә» мөрәҗәгатендә әдип Татар театр техникумының яшь артистларны укытуда дөрес юл белән бармавына чаң суга, пьесалар конкурсына бәяләмәдә әдәбиятның гомуми хәле өчен борчыла.

Фатих Әмирханга язылган хатлар да, әдипнең үзенеке шикелле, нечкә юморга бай. Әйтик, Борһан Шәрәф хаты (1907, 1 апрель) авторының үз-үзеннән көлү төсен алган. Яки Кәбир Бәкер хаты (1908, 6 июль) Әхмәтһади Максудиның вакытлы матбугатта Садри Максудины мактарга яратуыннан бик оста көлә: «Юрист, фәкыйһ, мөхтәрәм Садретдин әфәнде Максуди җәнабе галиләре, Һади абзый хәбәр бирүенә караганда, бөтен парламент исеменнән Франциягәме, әллә кайда гына, хәтеремнән чыккан, бара, ди. Думада аннан башка французчага оста кеше булмаган икән».

Әмирханга хатларда татар дөньясының проблемалары кузгатыла. Борһан Шәрәф 1908 елның 11 сентябрендә Оренбургтан язган хатында татар әдәбияты тарихын язуның мөһимлеген күтәрә: «Татар әдәбияты тарихы һәм ысулын язуны да сөйләшеп уздырган идек бугай. Аны да татарча белми торган, яисә бер әдәбият тарихыннан да хәбәрсез кешеләрдән көтәргә ярамый» [6: 117]. Кәбир Бәкер (1908, 30 июнь) [6: 121], Вафа Бәхтияров (1908, 9 июль) [6: 126] хатларында «Әлислах»ны чыгару, аның эчтәлеген баету, финанс мәсьәләләре кузгатыла.

Габдулла Тукайның 1908 елның 23 июнендә язган хаты Әмирхан белән шагыйрь мөнәсәбәтләре туганнарча булуын күрсәтә. Бу хатта бик якын кешегә генә зарлану да («Үзем хәзер бернәрсәне дә, беркемне дә сөймим»), күңел сызлавыгын ачып салу да («“Йа Рабби! Ятимлекләр, фәкыйрьлекләр, ачлыклар, авылдан авылга сатылып йөрүләр, рәхимсез татар байларында хезмәт итүләр, татар мәдрәсәсендә черүләр арасында да саклап килдекем истигъдад очкыны шушы исереклекләр, исерек иптәшләр арасында бер дә кабынмаслык булып сүнәрмени инде?” – дим»), Оренбургка бару-бармау мәсьәләсендә киңәш сорау да, өметләр белән уртаклашу да («Монда “Әлислах” ходка китсә, көлке журналы да чыкса, үземнең кальбән сөйгән гәзитә вә идеямә хезмәт итәр идем») бар [9: 202].

Габдулла Тукайның соңгы хатлары (1913, февраль һәм 18 март) шагыйрьнең үз сәламәтлеген түгел, татар мәдәниятен кайгыртуын, яшәргә көчле омтылышын күрсәтәләр [9: 236–237].

Дуслары Әмирханның да гел татар халкы ихтыяҗларын кайгыртып, үз саулыгын онытып яшәвенә көенәләр. Әйтик, Исмәгыйль Аитов хаты (1908, 27 сентябрь, Оренбург) – шундыйлардан. «Минемчә, син бүгеннән башлап, чыннан үз исәнлегеңә күз салырга тиеш, аның өчен башка хезмәтләрне куеп торырга тиеш (курыкма, милләт сине ташлап китә алмас, бер гасыр йоклап торсаң да, “Әлислах”ны беренче номердан башлап чыгарырга туры килер). Берәр җиргә – суга, диңгезгә барырга кирәк. “Акча мәсьәләсе” – юк мәсьәлә. Иренмичә, ислахга җыйган куәтең ярымын гына сарыф кылсаң да, үзеңне тәмам терелгәнчегә җитәрлек таба аласың. Булмаса, болай ислахка дарым “Алла ризалыгы” өчен, яисә милләт өчен хезмәт итеп, үзеңне бетереп, тагын катырак авыру булып, ахыры үлеп китү, әллә ни вакыт үткәч, татар исенә төшерәме? Төшерсә, һәм ни файда... шулай, иптәш, ташла һәммәсен, үзеңне карарга башла» [6: 136], дип эндәшә ул тормышын милләткә хезмәткә багышлаган дустына.

Әстерханнан Шәһид Гайфи (1910, 12 декабрь) исә, ихластан, авыру әдипне үзе торган авыл янындагы шифаханәгә дәваланырга чакыра [6: 175].

Әмирхан милләт кайгысын кайгыртудан, аерым йогынтылы кешеләргә бу хакта язып торудан туктамаган, билгеле. Әхмәд Исхакыйның 1908 елның 6 октябрендә Орскидан җибәргән хаты, мәсәлән, әдипнең аңа, «Шәрык китапханәсе» проектларында, җитди әсәрләр бастыру киңәшенә җавап итеп язылган [6: 134].

1908 ел, 22 ноябрь датасы куелган билгесез мөселман хаты – татарларның «Әлислах»ны таратуда булышлыгы, төбәкләрдә ислахчыларга мөнәсәбәт, мәдрәсәләрдә укыту программалары кебек мәсьәләләргә кагыла [6: 159]. Бу хат – татарларның уртак вазгыятьтә актив катнашуына дәлил дә. Томскидан Ибраһим Бикколов хатлары [6: 142] да Казаннан читтә яшәүче татарларның Әмирханнан фикер дә, ярдәм дә көтүе хакында сөйли. Вагыйз Нәүрузов (1911, 31 декабрь) Томскидан үзе чыгарырга исәп иткән «Сибирия» газетасын «каләмегез илә поддержать итегез» дип үтенә.

Фикердәшләреннән килгән хатларда Ф. Әмирханның әдәби әсәрләрен яратып укулары күренә. Көтелмәгән матур фикерләр дә шактый. Хәлил Әбелханов (1912, 1 март) «Хәят»ка шактый каршылыклы бәя бирә, аның «“Михаил малай”ның уң кулы берлә Хәятның сул кулыннан йомшак кына тотканда, Михаилның кулына сугасы килә» кебек җөмләләрен елмаймыйча укып булмый [6: 137]. Саратов губернасы Кузнецк өязе, Кынадыдан Йосыф Казаков хаты (1912, 17 апрель) бик җентекле күзәтүләре белән аерылып тора. Аның «Татарлыкта да чынлап яшәп була икән!» дигән сүзләре повестька олы бәя булып яңгырый. «Инде бу замангача үзенең ярлылыгы илә мөттәһәм тотылган татар телен һәм шулай ук эштән чыгарга якынлашкан

татар хәрефләрен үзләренең булгылыклары илә укып туймаслык татлы “Хәят”ны вөҗүдкә чыгара алганлыклары өчен һәм татар әдәбияты “Хәят”ны танып, мәйдане интишарга куйганлыгы өчен боларның һәркайсын җитди хис илә тәбрик итәмен! Яшәсен татар теле! Бозылмасын татар хәрефләре! Рәваҗ тапсын (эчендә “Хәят”ы булган) татар әдәбияты!» дип шатлана автор [6: 139].

Үзләре татар дөньясы, милли әдәбият язмышы хакындагы хезмәтләр дәрәҗәсендәге Гаяз Исхакый хатлары татар мәдәнияте тарихына кызыклы мәгълүматлар алып килә. Мәсәлән, 1912 елның 13 июнендә Мезеньнан язган хатында [7: 14, 15–17] ул Максим Горькийның үзенә татар язучылары әсәрләре тәрҗемәләрен җыеп бастыру тәкъдиме ясаганлыгын әйтә. Шул дәвер әдәбиятын яхшы белгән Исхакый әдәби барыштагы иң көчле дүрт авторны аерып алуын белдерә: үзе, Ф. Әмирхан, Габдулла Тукай һәм Сәгыйть Рәмиев. Исхакый Әмирханга әлеге иҗатчыларны бәяләвенең дөресме-түгелме икәнен сорап мөрәҗәгать итә. Димәк, бу өлкәдә Әмирханны үзенә караганда да мәгълүматлы һәм зәвыклы таба.

Моннан тыш, Исхакый Тукай шигырьләрен сайлап алу мәсьәләсендә дә Әмирханнан киңәш сорый. Җыентыкка әсәрләр сайлауның асыл максатын аңлатып, болай ди: «Минемчә, бөтен әсәрләрдән, кирәк шигырь булсын, кирәк нәсер булсын, татар исе, татар тормышы аңкып торырга тиеш».

Хатның ахырында Исхакый Әмирханның соңгы әсәрләренә дә мөнәсәбәт белдереп уза: «“Урталык”ны укып чыктым. Матур башлана, ләкин “Хәят” аңардан “тормышлы”рак. Аңардан куәтлерәк тел берлән язылган. Хәсәнең әле бик уртача кеше, бара-бара бәлки ачылыр. Ачылыр да татар тормышының чәвирүчеләре (ягъни үзгәртүчеләре) арасына керергә хак казаныр. Икенче, өченче җөзләре чыкса, әлбәттә, җибәртерсең. “Хәят”ны тизрәк бетер».

5 август хаты [7: 18–21] Ф. Әмирханның Исхакый тәкъдимен кабул иткәнлеге хакында сөйли. Әсәрләр сайлау мәсьәләсе хакында сөйләшүне дәвам итеп, Исхакый Тукай иҗаты хакында болай ди: «Татар әдәбиятында аның тоткан урыны бик зур булганга, русларга күрсәткәндә дә төрле ягыннан әйләндеребрәк, ялтыратыбрак күрсәтәсе иде». Ф. Әмирхан иҗатына караш та кызыклы: «Ләкин синең үз әсәрләреңне татарларның руслашкан тормышыннан алынган дип, читкә кагып, ташларга теләвеңә разый түгел. <…>, алар – татар тормышы. Син үзең – яза торган дәвернең чын баласы, шул дәвернең психологиясен иң белә торган мөхәррире». Бу сүзләрдә Ф. Әмирханның үз әсәрләренә икеләнүле мөнәсәбәте һәм Г. Исхакыйның аның иҗатына югары бәясе аермачык.

Кабат рус телендә җыентык әзерләүнең мөһимлеге мәсьәләсенә әйләнеп кайтып, ул болай дип яза: «Минемчә бит, без шул мәҗмуга берлән русларга каршы: “Ниндиләр менә бездә бар. Без дә торырга телимез, тормакчы да буламыз. Яшәргә юллар да эзлимез. Табылганнарын аллы-гөлле маяклар утыртып, киңәйтеп, турайтып, алдагы

юлга чыгармакчы буламыз”, – дип кычкырырга телимез. Вә шуны ишеттерергә тырышамыз. Бәлки максадка ирешә алмабыз. Ләкин шул мәҗмуга, шөбһәсез, шул юлда салынган күперләрнең иң беренчесе, бәлки, иң ныгы булачак». Кызганычка каршы, зыялылар вакыт һәм көч салып әзерләгән бу җыентык дөньяга чыкмый кала!

Күрәсең, Ф. Әмирхан дүрт әдип янына Г. Ибраһимовны, Ш. Камалны да кертергә тәкъдим итә. Моңа каршы Исхакый: «Ул (ягъни Ибраһимов) әле татарларның беренче мәҗмугаларына керү хакын казана алган кебек күренми. Тагы шуны әйтеп китәм, ул кеше хәзер русларның “елакчы” әдәбиятларының тоткарлыгында яши булырга кирәк. Әсәрендән өмидсезлек чыгып тора. Шәриф Камалның да миңа иң ярамаган йире – шул еглау тавышының бөтен тавышларны җиңеп китүе. Аның матур самими әсәрләре әллә кая әрәм була. Тап-таза киң җилкәле Фәйзулла абзыйсы үлә. Анасы берлән килешә алмаган яшь хатыны югала... Хаслы тормыш матур башланса да, ямьсез бетә, үлә, корый, кибә, оча... Менә шул “өмидсезлек” минем карашымдан татар әдәбиятына “елавык” руслардан кертелгән, татар рухына аз гына да охшамый торган, кирәкмәгән зарарлы буяу гына. Безнең тормышымызда (минем күрүемчә) мескинлек, булдыксызлык хәятның үзәге түгел. Ара-тирә очрый торган бәхетсезлек кенә. Шуның өчен, шул ноктага иң зур нокта итдереп тотып, бөтен тормышны шундан ага торган зәһәрле буяуга буярга тырышу – минемчә, зур хата. Татар халкының истикъбали карашындан җинаять! Истанбулда төрек дәрнәгендә укыган рефератымда мин татар әдәбиятының аерынгы бер галәмәте – аның егламавы, ныклыгы, тазалыгы, тормышның начарларына, зәһәрләренә каршы чыгуына ышанып, күкрәкне киереп, йырлый-йырлый сугышуы дип, рефератымны бетергән идем. Шул сүзләрне мин тәмам ышанып әйткән идем. Хәзер менә шуңарга ышанам. Татар китап мәйданына чыккан бөтен әсәрләрдән шул фәйзъне ныгыта торган дәлилләр эзлим. Бик күбесендән табам. Никадәр өмидсез күренсә дә, Сәгыйдьнең шигырьләренең һавалылыгын төшен. Габдулланың арый белмәгән шигырьләрен укы. Һәммәсендән яңа пешкән арыш икмәге исе чыгып тора, һәммәсендән үзенә үзе ышану нуры балкып тора».

Бу өзектән Г. Исхакыйның 1912 елда татар әдәбиятына, татар язучысына нинди таләпләр куюы ачык аңлашыла. Сентименталь әдәбият, тәнкыйтьләүче, дөньяны каралтып күрсәтүче әсәрләр вакыты узды, хәзер татар дөньясында өмет бирә, идеалларны тасвирлый, киләчәккә юллар сыза, якты киләчәк өчен көрәшкә рухландыра торган әдәбиятка ихтыяҗ туды, ди ул.

Әмирханның үз хәяты, укуын дәвам итү теләге хакында фикер соравына Исхакый болай җавап бирә: «Синең аттестатка тоту мәсьәләсе – әлбәттә, үз эшең. Университетка кереп, тюркология хакында мәгълүмат җыю, әлбәттә, хәзер безнең өстә. Фарыз киңәя. Ләкин имтиханның авырлыгы, сарыф кылынган вакытның әрәмлеге төшенелсә, шуны ыргытып, слушатель булып керү генә ярамыймы

икән? уе тугры кебек күренә. Тагы, шуның өстенә, син бит шулай инде, мөхәррир булып китү юлына, шул юлда үлү юлына аяк баскан. Төрек-татар тарихы берлән маташуны бүтәнгә бирсәң, әлбәттә, эшләмәгән булмассың. Шуңарга кул селтәсәң ярамыймы? Тагы, минемчә, ул юлда хедмәт итәргә теләгән кешегә, мотлакан, Петербургка килергә кирәк. Алар синең өчен бик авыр. Мөмкин булса, шул юлга син Габидуллинларның берсен төртергә тырыш. Акча да бар, дәрд дә булса, әлбәттә, эш чыгар».

Бу өзектәге «Габидуллиннарның берсен төртергә тырыш» дигән сүзләрдә Г. Исхакый белән Ф. Әмирханнарның бергәләп татар дөньясына файдалы эшләр хакында фикерләшүе, киңәшләшүе күренә.

Бу хатта Ф. Әмирханның яза башлаган яңа романы хакында сөйләшү дәвам итә. «“Урталыкда” синең тәкъдиреңчә булса, әлбәттә, минем могарәзәләрем килми. Ләкин аны укучылар шулай син теләгәнчә аңлаячакლармы? Каһарманлары күрсәтелмәгән тарихи бер вакыйганың корбанларындан башларга ярыймы? Сөальләре җавапсыз калмыймы? Минем “Тормышмы бу?”, “Фамилия сәгадәте” хакындагы фикерләрең кыйсьмән дөрест. Ләкин шуларда бит <...> генә әһәмият бирелмәгән, бер татар шәкерденең бөтен тормышы, рухы күрсәтелергә, тәхлил ителергә тырышылган. Муаффәкъ булу-булмау – икенче мәсьәлә». Монда да Исхакый татар дөньясының «корбаннарын» гына түгел, беренче чиратта «каһарманнарын» үзенә күрсәтү мөһимлекне искәртә. Хәтта тормыштагыга тәңгәл-туры килмәсә дә, милли әдәбиятның кавемдәшләре аңына тәэсире алда тотылырга тиешлеккә игътибар итә.

Шушы ук хатында Исхакый татарча әдәби журнал («Аң» турында сүз бара) булдыру хыялы турында яза. «Шуны басдыра алсак, татар тормышына да тәэсиремез артыр иде», дип, моның татар зыялылары өчен уртак омтылыш булуын дәлилли.

18 сентябрь хатында [7: 21–23] Исхакыйның 1912 елдагы сәяси карашларын аңлатуы кызыклы. Ул татар халкы үсешен, Россияне үзгәртеп коруда аларның да актив катнашып, яңа нигезләрдә уртак дәүләт коруда күрә. Реакция машинасының илне җимерү мөмкинлеген фараз итеп, болай ди: «Безнең вазифамыз хәзер – мөмкин кадәр шуның юлыннан читкә китеп калып, тарих ташына барып бәрелеп, пыран-заран килгән рус машинасының ватыкларын җыешканда хәзер булып, куәтемез, көчемез зурлыгымызга мөнасиб ватыкларны кулымызга алып, шул машинаны яңадан юлга салганда үз маемызны да кушарга тырышу...». Шул караштан яңа программа, яңа план ясыйм, ди ул.

Үз эшләрен, аерым алганда, Муса Бигиевнең татарча Коръән бастыруына каршы килүен ул татарларга, мәдәни көчеш чорында, диннең авыр аңлашыла торган гарәп телендә булуы файдалы дип шәрехли. «Әхми агайларны, Миңлесафа абыстайларны милли әдәбиятымыз берлән бергәләштергәнчегә кадәр, шул Коръән җеп берлән тегелгән букчамызны сүтмәенчә торуны, әлегә шуның бер кырыеннан гына

әдәбият кертә-кертә маташуымыз хәзерге хәлемез өчен тиеш вә лязем дип уйлыйм. Шуның өчен, Мусаның хакыйкатән файдалы вә кирәкле эшендә гомум халкымыз файда итәр урында (вакыты җитеп бетмәгәнгә күрә) хәзер зарар гына итәр дип иман китерәм. Вә шул сәбәптән Мусага сүз аңлату кабил булса иде. Мин, мотлакан, шул тәрҗемәне бастыруны, ичмасам, 1925 елга кичектерер идем». Бәхәсле булса да, бу сүзләрдәге логиканы күрмәү мөмкин түгел.

Ф. Әмирханга гади укучылар язган хатларның да шактый күләмле, эчтәлекле, проблемалы булуын әйтергә кирәк. Мисалга, Кояш Җәббарова 1915 елның 10 февралендә «Тигезсезләр»дән алган тәэсирләре белән уртаклаша. Әсәр «минем күңелемдә әллә нинди яңа бер хисләр тугдырды», «ул мине шатландырды, кайгыртты» дип, ни өчен шатландыруын, ни өчен кайгыртуын аңлата һәм хатын мондый матур теләкләр белән йомгаклый: «Рәхмәт, Фатих абый! Мең, мең рәхмәт. Тагын да шундый күп, күп пьесаларыны шатланып, шатланып чыгаруыңызны, бәхетле вә рәхәт булып озак, озак яшәвеңезне теләп, ихтирам илә кызыгыз Кояш Җәббарова» [6: 173].

Ф. Әмирханның татар мәдәни галәмендә йогынтылы, фикере зур әһәмияткә ия, рухи әйдәман булуын дәлилләп килгән хатлар да аз түгел. Шундыйлардан, мәгълүм шәхес Камил Мотыйгыйның хаты (1915, 28 июль) – әдипкә турыдан-туры катнашы булмаган, Уфада нәшер ителгән «Тормыш» газетасы белән килеп чыккан аңлашылмаучылыкны чишәргә ярдәм соравы, үзен яклап мәкалә язуын үтенүе – моңа дәлил була ала [6: 143].

Берничә хат 1915 елда Ш. Мәрҗанинең тууына 100 ел тулуга багышлап, «Мәрҗани» исемле җыентык әзерләүгә кагыла. С. Гобәйдуллин бастырып чыгарган, 1913 елдан материаллар җыюны Шәһәр Шәрәф, имам-хатыйп Кәшшафетдин Тәрҗемани, Габдулла Гыйсмәти, Газиз Гобәйдуллиннар оештырган бу игелекле эштән Ф. Әмирхан да читтә калмаган икән. Әлеге хатлар янәшәсендә әдипнең «Кояш» газетасындагы «Мәрҗани хатирәсенә мәҗмуга» исемле мәкаләсе шушы эшнең ноктасы кебек кабул ителә.

Ф. Әмирхандагы күренекле шәхесләрне татар дөньясына таныту максатыннан китаплар әзерләү фикеренең инкыйлабтан соң да үсеп баруын Риза Фәхреддиновның 1919 елгы 9 февраль хаты раслый.

Әлбәттә, Ф. Әмирхан татар дөньясында барган күп эшләрне белеп, аларга турыдан-туры яки җылы сүзе белән катнашып яшәгән. Таһир Ильясиның 1921 елның 16 гыйнвар хаты да шул хакта: автор «Татарча-гарәпчә» сүзлеген тәмамлап, бер өлешенең басылып чыгуын хәбәр итә һәм, киңәшкәндә эшкә дәртләндереп торган өчен, әдипкә рәхмәт әйтә [6: 174].

Әлбәттә, 1917 елгы үзгәрешләрдән соң да татар мәдәни җәмгыяте Әмирханның ярдәменә мохтаҗ булып кала. Идел-Урал Мөселман халык комиссариаты әгъзасы Әфтахетдин Габидуллинның 1918 елгы 17 март хаты шуны сөйли [6: 163]. Ченәкәй (Төхфәтулла Гыйззәтулла улы Гыйззәтуллин) 1921 елның 16 гыйнварында язган хатында,

олылап, әдипкә «Ил әдәбиятының йолдызы Фатих әфәнде Әмирхан!» дип эндәшә. Бу хат – исеме, иҗаты бик аз билгеле шагыйрь, тәрҗемәченең шигырьләрен саклавы белән дә кадерле.

* * *

«Документлар» бүлеге дә гаять бай. Ул Ф. Әмирханның әтисе Мөхәммәтзариф Әмирхановның әтисе (Фатихның бабасы) Хөсәен Әмирханов янына Яңа татар бистәсенең икенче мулласы булып сайлануы хакындагы 1874 елгы документлардан (рапорт, беркетмә, прошение һ. б.) башлана. Алар татар дин әһелләре тормышына шактый ачыклык кертә. Әйтик, 1874 елның 5 ноябрендә Казан Губерна идарәсе, Казандагы өченче мәчеткә икенче мулла итеп сайлау хакында мәхәлләнең карары булса да, егеткә 22 яшь тулмаганлыкны (бер айдан артык вакыт калган була) һәм солдатка каралу ихтималын күрсәтеп, тискәре җавап бирә. Россия законнары буенча, бердәнбер бала буларак, солдаттан калырга хокуклы Мөхәммәтзариф Әмирханов хәрби чакырылышка бара, ополчениегә язып куела. 1875 елның февралендә Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургиядә имтиханнар тоткач (мәхкәмә аның имам, имам-хатыйп, мөдәррис була алуын раслый), Губерна идарәсендә ант биргәч, 1875 елның 20 июнендә мулла итеп тәгаенләнә. Бу документлар империя чорында әлеге вазифага керешүнең шактый сынау-катлаулылыклар үтеп кенә мөмкин булуы турында сөйли.

Документларның күпчелек өлеше Ф. Әмирхан тормышына карый (уку таныклыклары, метрика белешмәсе, хәрби хезмәт хакында белешмәлек һ. б.). Әләк, җасуслык, шуның нәтиҗәсе буларак Ф. Әмирхан һәм Ә. Хәсәни өйләрендә тентүләр, алар өстеннән күзәтү оештыру турындагы кәгазьләр әдип тормышының аерым бер этапларына ачыклык кертә.

1917 елдан соңгы документлар арасында Милләтләр эшләре буенча халык комиссариаты каршындагы Бөтенсоюз фәнни ассоциациясенең Тарих-этнология бүлегенә әгъза итеп сайлануы хакындагы, Татар театр техникумында татар әдәбияты укыту турындагы белешмәләр игътибарны җәлеп итә.

1924 елның 9 маенда Академүзәк редколлегиясе Ф. Әмирханның нәшер итүгә дип сайлаган җыентыгын кире кайтара. Г. Толымбай әзерләгән рецензиядә әдипнең «Чәчәкләр китерегез миңа!», бүгенге укучыга «Тәгъзия» һәм «Беренче ашкыну» исеме белән мәгълүм хикәяләре «эшче-крестьян укучыларга бернинди файда китермиләр һәм аларны бастыру әдәбияттагы реакцион юнәлешкә ярдәм булыр иде», диелә. Моны ишеткәч, Әмирхан аларны үзе кире ала. Әлеге документлар 1925 елда Ф. Әмирхан көндәлекләренә кушымта итеп теркәлгән материалларның нинди шартларда дөньяга килүен аңларга да ярдәм итә.

1925 елның июнендә ТССР Нәшрият һәм матбугат комбинаты кабат Әмирханнан әсәрләр җыентыгын кабул итеп ала, монда инде

инкыйлабка кадәрге авыр тормышны күрсәтерлек әсәрләр туплана: «Тигезсезләр», «Татар кызы» һәм «Халык кызлары».

1925 елның августында Әмирханга персональ пенсия билгеләнә. Әмма бу вакытка инде әдипнең сәламәтлеге начарланган була.

Әдипнең 1926 елның 9 мартында вафатыннан соң Галимҗан Шәрәф, Ибраһим Бикколов һәм энесе Ибраһим Әмирханнар әзерләгән акт кәгазе «Гакыднамә» «мәрхүмнең фатирында табылган бөтен кулъязмаларын, хатларын, мәрхүмнең тәрҗемәи хәленә һәм исемен мәңгеләштерүгә бәйләнеше булган сәнәдләрне, китапларны, рәсемнәрне, кием-тотым һәм җиһазларны вә бөтен материалларны барлап» язып алынган. Анда 47 пункттан гыйбарәт кулъязмаларның күләме, кайчак геройлары, жанры теркәп куелган. Мондый зур хезмәтне башкарып, әлеге татар зыялылары Әмирханның язма мирасын саклауга зур өлеш кертәләр. Әмма бу урында да күп кенә язмаларның язмышы бүгенге көнгә кадәр билгесез калганлыкны әйтергә туры килә.

6 нчы томга кушымта итеп урнаштырылган материаллар бик уңышлы сайланган һәм документлардагы язмаларны тагын да төгәлләштерәләр. Язучының якын дусты, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Кәрим Сәгыйтьнең «Атаклы татар әдибе Фатих Әмирханның авыруы, үлүе, күмелү мәрасиме» истәлеге – татар әдәбиятындагы мондый төр материаллар арасында иң баедыр. Элегрәк ул «Рухи мирас» [6: 220–267] сериясенең икенче китабында нәшер ителсә дә, киң катлау укучыга билгесез булып кала иде. Анда язучының соңгы көннәре җентекләп күзәтеп узыла, бу күзәтүдә татар халкының, Казан кешеләренең аерым төркемнәренең аңа ихтирамлы мөнәсәбәте дә, әдипнең олылыгын аңлау да, Әмирханның сабырлыгы һәм рухи ныклыгы да аермачык күренеп тора. Соңгы юлга озату, бу эшнең ничек оештырылуы, коммунист һәм партиясез зыялыларның позициясе турындагы бәян чор картинасын тергезә. Истәлектә Ф. Әмирханның халык мәхәббәтен һәм ихтирамын яулаган язучы, милләтпәрвәр булып дөньядан кичүе турындагы фикер үзәккә куела.

Тагын бер материал – Равил Әмирхановның Әмирханнар нәселенә багышланган китабыннан алынган өзекләр [11]. Бередә татар халкына күренекле әдипне бүләк иткән затлы нәсел, аның талантлы вәкилләре турында да, гаиләдәге мөнәсәбәтләр, Ф. Әмирханның тормышы хакында да күп кенә кызыклы материал табарга мөмкин.

Китапның зур бер өлешен «Искәрмә һәм аңлатмалар» бүлеге тәшкил итә. Алар бай, бөртекләп эшләнгәннәр, чыганаклар хакында шактый тулы, тирәнтен мәгълүмат бирелгән. Моның өчен төзүчеләргә аерым рәхмәт белдерергә кирәк.

* * *

Шулай итеп, Фатих Әмирхан «Әсәрләр»енең алтынчы томы үзенең байлыгы, әдип хакында моңа кадәр билгеле булган, алдагы томнарда җиткерелгән мәгълүматларны киңәйтүе-тирәнәйтүе белән

аерылып тора. Әдәби-публицистик иҗатындагы көчле рухлы, үткен телле, зыялы, тирән аң-фәһемле, вакыты белән усал, киң карашлы, югары зәвыклы, оптимист Фатих Әмирхан образына бу том яңа сызыклар өсти. Биредә нечкә күңелле, хаксызлыкларга сизгер, юморга бай, дусларына һәм танышларына һәрчак рухи терәк тә, акыллы киңәшче дә була алган шәхес сурәте калкулана. Авыруына, тормыш китергән сынауларга карамыйча, ул үз мәсләгенә – халкына хезмәт итүгә, аны мәдәни-иҗтимагый үстерүгә, татар әдәбиятын баетуга, татар дөньясын яраткан яшьләр буынын тәрбияләүгә тугры кала.

Фатих Әмирханның 6 томлы «Әсәрләр»е затлы татар әдибе, журналисты, әдәбият галиме, фикер иясе, философ, эстет шәхесне, аның бай иҗат мирасын бүгенге көн тулылыгында, XXI гасыр фәне югарылыгында халкыбызга, мәдәниятебез тарихына кайтаруы белән әһәмиятле. Бу олы эшне башкарып чыккан галимнәргә – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге хезмәткәрләренә зур рәхмәт.

**Әдәбият**

1. *Әмирханов М.-Ф. М.-З.* Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. 1 т.: хикәяләр һәм повестьлар (1907–1911) / [төз., иск. һәм аңл. әзерл.: Э.М. Галимҗанова, Ф.Г. Фәйзуллина; кереш сүз авт. Д.Ф. Загидуллина]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2024. 509 б.

2. *Әмирханов М.-Ф. М.-З.* Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. 2 т.: хикәяләр (1912–1924) / [төз., иск. һәм аңл. әзерл.: Г.Н. Зәйниева, Г.А. Хөснетдинова]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2024. 415 б.

3. *Әмирханов М.-Ф. М.-З.* Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. 6 т.: Көндәлек язмалар, хатлар, документлар / [төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. Э.М. Галимҗанова, Г.Н. Зәйниева, Г. А. Хөснетдинова]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2026. 526 б.

4. *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: Унбиш томда. 6 т.: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1914) / [төз., иск. һәм аңл. әзерл.: З.Г. Мөхәммәтшин; кереш сүз авт. Д.Ф. Заһидуллина]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. 327 б.

5. *Ибраһимов Г.* Әсәрләр: Унбиш томда. 13 т.: Публицистика (1907–1918) / [төз., иск. һәм аңл. әзерл.: Ф.Г. Фәйзуллина; кереш сүз авт. Ә.А. Гатин]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2021. 421 б.

6. Духовное наследие: поиски и открытия / под ред И.Г. Гумерова. Казань: ИЯЛИ, 2016. Вып. 2. 300 с.

7. *Исхакый Г.* Әсәрләр: 15 томда. 14 т.: хатлар һәм автобиографик язмалар / [төз., иск. һәм аңл. әзерл.: Ф.Г. Фәйзуллина]. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 479 б.

8. *Тукай Г.* Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. 4 т.: проза, публицистика (1907–1913) / [төз., иск. һәм аңл. әзерл.: З.Г. Мөхәммәтшин]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 431 б.

9. *Тукай Г.* Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. 5 т.: мәсәлләр. Балалар өчен хикәяләр. Автобиографик повесть. Юлъязмалар. Хатлар (1903–1913) / [төз., иск. һәм аңл. әзерл.: Г.А. Хөснетдинова, Г.М. Ханнанова]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 415 б.

10. *Әмирхан Ф*. Әсәрләр: дүрт томда. 4 т.: әдәбият-сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 390 б.

11. *Әмирхан Р.* Әмирханнар (тәфсилле шәҗәрә). Казан: Мәгариф, 2005. 125 б.

***Заһидуллина Дания Фатих кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*әдәбият белеме бүлеге баш гыйльми хезмәткәре*

***Загидуллина Дания Фатиховна,***
*доктор филологических наук, профессор, главный научный сотрудник*
*отдела литературоведения Института языка, литературы*
*и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*zagik63@mail.ru*